**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ СТАРОУТЯМЫШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423105,Черемшанский район,
с.Старый Утямыш, ул.Мусы
Джалиля, дом 52

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ИСКЕ ҮТӘМЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

423105,Чирмешән районы Иске Үтәмеш
авылы, Муса Җәлил урамы, 52 нче
йорт

тел./факс 8-84396-2-37-16 email: Sut.Cmn2@tatar.ru

№116 20.12.2023 ел.

«Чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән өчен түләтүләр, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турында таләпләр һәм коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен түләтүләрне куллану тәртибе турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлегенең 2013 елның 12 февралендәге № 59 карарына үзгәрешләр кертү хакында

2023 елның 13 июнендәге № 258-ФЗ, 2023 елның 10 июлендәге «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» № 286-ФЗ Федераль законнар, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. «Чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән өчен түләтүләр, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турында таләпләр һәм коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен түләтүләрне куллану тәртибе турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлегенең 2013 елның 12 февралендәге №59 карарына (Советның 2021 елның 30 сентябрендәге №40, 2023 елның 10 мартындагы №85, 2023 елның 29 июнендәге №95 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.4 пунктчасының 2 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «үз карамагындагы муниципаль хезмәткәрдә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында белгән яллаучы вәкиле булган муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча чаралар күрмәве, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш;».

1.2. 2.5 пунктның 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: «1) федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәтенең кадрлар бүлеге үткәргән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Иске Үтәмеш авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Р.С.Мингулов